СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.04.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48 40-229

с. Нижний Услон

Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге
Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын
2023 елның 10 декабрендәге 2 номерлы гражданнар җыенына
үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 декабрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга;

«Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән сез килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Завод урамындагы су башнясын ремонтлау һәм буяу)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Түбән Ослан авылы Беренче Май урамы буенча 77 нче номерлы йорт янында 10.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В. Архиреев